**Көн темасына әңгәмә**

**Район прокуроры А.П.Евграфов белән чираттагы әңгәмәбезне 1997 - 98 елларга районда җинаятьчелеккә каршы көрәшнең район эчке эшләр бүлеге тарафыннан эшләнгән комплекслы программасы турында сөйләшүдән башларга булдык. Ул мәсьәлә әле күптән түгел генә халык депутатлары район Советының чираттагы сессиясендә каралган иде.**

# ТЫРЫШЛЫКНЫ БЕР МАКСАТКА ТУПЛАП

***- Александр Петрович, сессиядә чыгыш ясап, Сез депутатларга икееллык ул программаны кабул итәргә киңәш иттегез...***

- Шулай кирәк иде ул. Программа җинаятьчелеккә каршы көрәштә хокук саклау органнарының, җирле үзидарәләрнең, хезмәт коллективларының, җәмәгатьчелекнең тырышлыгын бергә тупларга тиеш. Программаның төп моментларыннан берсен - профилактика эшен аерып күрсәтергә телим. Җинаять эшләүләрнең сәбәпләренә төшенү, аңа җирлек биргән шартларны белеп тору, кыскасы, аларны кисәтү дигән сүз бу. Һәм болар бер милициянең генә түгел, ә бөтен җәмгыять эше.

***- Ә прокуратураның роле турында нәрсә әйтә аласыз?***

- Аның вазифасы законлылыкның торышына прокурор надзоры алып барудан гыйбарәт. Бу хакта безгә район буенча системалы рәвештә, ә җинаятьләр һәм хокук бозулар турында эчке эшләр бүлегеннән көндәлек мәгълүмат кереп тора һәм алар анализланып, законнарны үтәү буенча гамәли чаралар күрелә.

***- Ул яктан ел башыннан хәл нинди?***

- Бу чорда 12 гаепләнүчегә карата 15 җинаять эше судка җибәрелде. Аларның алтысы - усал ният белән үтерүләр, шул исәптән ике хатын - кызны - Маликова белән Гәрәеваны үтерү буенча, икесе - авыр тән җәрәхәте ясау, икесе - көчләү буенча.

***- Җинаятьчелеккә каршы көрәштә нинди проблемаларны аерып күрсәтә алыр идегез?***

- Көнкүреш җинаятьләре, ягъни гаепләнүче дә, каза күрүче дә элек үзара таныш, күршеләр, хәтта туганнар булган очраклар артуга бара. Кагыйдә буларак, күпчелек җинаятьләр аек булмаган кешеләр тарафыннан эшләнә. Кыскасы, пычак эшкә җигелә икән, монда инде күпчелек очракта исереклек сәбәп булып тора.

***- Александр Петрович, ә балигъ булмаганнар арасында эшләнә торган җинаятьләргә карата фикерегез ничек? Күптән түгел 4 нче мәктәптә булган очрак бөтен кешене тетрәтте бит.***

- Бу - сирәк очраклар рәтенә керә торган хәл. Аның буенча тикшерү дәвам итә әле. Ә инде яшүсмерләр арасында җинаятьчелекнең гомуми торышына килсәк, тугыз айда андый җинаятьләр дәрәҗәсен киметүгә ирешелде. Быел балигъ булмаганнар тарафыннан 13 җинаять эшләнде һәм бу узган елның шул чорындагыдан ике тапкырга азрак. Бу төр җинаятьләрнең тоткан өлеше 9,3 проценттан 5,2 процентка калды. Әмма авыр җинаятьләр саны артты. Өч көчләү очрагы, инде телгә алынган үтерү - борчылырга мәҗбүр итә. 9 җинаять ОППНда исәптә торучы үсмерләр тарафыннан эшләнгән.

***- Ә прокуратура хезмәт коллективлары турындагы законнарның үтәлешенә ничек күзәтчелек итә? Безнең район зур түгел, юридик зат статусына ия булган предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр саны өч йөзләп кенә.***

- Шуларга тагын 101 шәхси эшмәкәрне өстәгез. Соңгы ике елда районда юридик затлар саны утыз бермәлеккә артты. Гамәлдәге ассоциацияләрне үзгәртеп кору уңаеннан авыл хуҗалыгы кооперативлары санының кискен артуы көтелә. Күргәнегезчә, эш тыгызлана бара.

***- Үз эшчәнлегегездә башка органнар белән хезмәттәшлек итәсезме?***

- Шунсыз мөмкин түгелдер, чөнки без күп мәсьәләләрдә бер үк эшне башкарабыз бит. Район прокурорына салым инспекциясеннән, җир комитетыннан, авыл хуҗалыгы продуктлары хәзерләү һәм сыйфаты буенча инспекциядән, ветстанциядән, авыл хуҗалыгы идарәсеннән, контроль - ревизия идарәсеннән һәм башкалардан әледән - әле материаллар керә. Хезмәткә түләү буенча законнарның үтәлешен, пенсия һәм пособиеләрнең үзвакытында түләнүен һәм кайбер башка мәсьәләләрне без бергәләп тикшерәбез.

***- Болары турында азгына җентекләбрәк әйтсәгез иде.***

- Тикшерү нәтиҗәләре буенча МСОга, «Коопстрой» төзү участогына, «Сельхозтехника» АҖнә, Төрнәс спирт заводына, «Төрнәс» һәм «Үрнәк» хуҗалыкларына представлениеләр ясалды. «Сельхозтехника»ның элеккеге башлыгы хезмәткә түләү турындагы законнарны тупас бозганы өчен прокурор карары буенча административ җаваплылыкка тартылды. Эшләүчеләр файдасына 14,5 миллион сум хезмәт хакын эзләтеп алуга төрле оешмаларга 8 дәгъва белдерелде. «Үрнәк» хуҗалыгында ассоциация членнарының азык - төлек чекләры рәвешендә социаль түләүләргә хокукларын чикләүче карар ачыкланып аның буенча протест ясалды.

Тикшерүләр вакытында бюджеттан хезмәт хакы түләүгә бирелгән акчаларның максатчан тотылышы, пенсия бүлеге һәм социаль тәэминат бүлеге эшләре системалы рәвештә контрольдә тотылды. Хокук саклау органнарының координацион киңәшмәсендә шәһәрдәге 15 предприятие, оешма һәм учреждение җитәкчесенең шушы законнарның үтәлеше турында аңлатмалары тыңланды.

Прокуратура эшчәнлегендәге өстенлекле юнәлешләр турында сүзне дәвам итәргә дә мөмкин. Зүзәй нефть промыселында хезмәт турындагы законнарның ялга кагылышлы өлешенең үтәлеше, АТПда - балигъ булмаганнар хезмәтен оештыруның, нефтебаза ярдәмче хуҗалыгында хезмәтне саклауның торышы тикшерелде. Соңгысында шул законны бозганнары өчен баш зоотехник В.А.Калмыков белән ферма мөдире П.М.Семенов административ җаваплылыкка тартылдылар.

***- Акча түләү белән бәйле мәсьәләләргә дә тукталыйк әле. Салым һәм банк турындагы законнарны бозу очраклары бармы бездә?***

- Андый очракларны теркәдек без. Бу уңайдан салым инспекциясе дә катгыйрак эш итәргә һәм җәза чаралары күрергә тиешлеген әйтәсе килә. Алар бит законда каралган. Кайбер очракларда прокуратура килеп тыгылганнан соң гына банк структуралары җитәкчеләре җавапка тартылды.

Без шулай ук РСУда, ДРСУда, урман хуҗалыгында, «Надежда» дәүләт унитар предприятиесендә, элеваторда, спиртзаводта, җиләк - җимеш питомнигында, зооветснабта салым турындагы законнарны үтәүнең торышын да тикшердек. Дүрт очракта штраф санкциясе кулланырга туры килде.

***- Соңгы елларда урлау һәм караклык массовый төс ала бара. Монда инде дәрәҗәне дә аерып торасы юк. Прокуратура бу уңайдан нинди дә булса чаралар күрәме?***

- Урлаулар нәтиҗәсендә китерелгән зыянны каплау максатыннан ел башыннан156 миллион 621 мең сумга дәгъва белдерелде.

***- Хатлар күп керәме Сезгә? Мин иң элек халыктан керә торган шикаять һәм гаризаларны күздә тотам. Алар нигездә нинди характерда?***

- 9 айда гражданнардан барлыгы 53 шикаять керде. Нигездә алар торак турындагы законнарны бозу, шулай ук тикшерү һәм өстәмә тикшерүләр уңаеннан була.

***- Халык депутатлары район Советының Норлатны район буйсынуыннан республика буйсынуына күчерү турында Дәүләт Советына үтенеч белән чыгуына Сез ничек карыйсыз?***

- Уңай. Шәһәр үсә, проблемалар да күбәя. Безнең хезмәткә килгәндә исә икътисади һәм социаль өлкәләрдә, җирле үзидарә органнарында законнарның үтәлешенә контрольлек итү буенча эш күләме шулай ук сизелерлек арта. Безгә дә өстәмә штатлар кирәк. Әле менә район хакимияте башлыгы тарафыннан прокуратураның яңа административ бинасын салу турында карар чыгарылды.

**Т.НАЗАРОВА**
**сөйләште.**



Билгиз районда нефть чыгару оешмасы НГДУ ачылып, аңа бәйле рәвештә технологик транспорт идарәсе төзелүгә үк килде бирегә эшкә. Башта бульдозер машинисты иде, аннан тракторчы булды, берәр еллап контроль - үткәрү пунктында механик вазифасын башкарды. Инде трактор краны тракторчысы булып эшли башлавына да дистә елдан артык.

Билгиз Сәмигуллович үтә җаваплы кеше. Йорт хуҗасы, гаилә башлыгы буларак та дәрәҗәле ул. Эшендә дә сер бирми. Трактор краны белән нигездә төзелеш объектларында хезмәт куя ул.

**Рәсемдә: Норлат УТТсының 6 разрядлы трактор краны тракторчысы Б.ГЫЙМАЛЕТДИНОВ.**

**Н.КВАШНИНА фотосы.**

# ЯШЬЛӘР БЕЛӘН КӨЧЛЕ ХУҖАЛЫК

Хуҗалыкның кайсы гына тармагын алма, анда җир җимертеп яшьләр эшләп ята. Шулай . булмый мөмкин дә түгел. Чөнки авыл яшьләр белән матур булган кебек, хуҗалык та алар белән көчле бит. Мактаулы һөнәрне үз итүче «КамАЗ» автомашинасы шоферлары Фәнил Насыйбуллин, Айрат Нургалиев, Ришат Зәйдуллиннар, шулай ук уңган шоферлар Нәгыйм Гәрәев, Шәүкәт Гыйниятуллин, Наил Гәрәевлар һәм инде Норлат май заводына сөт ташучы тәҗрибәле шофер Ришат Гыйльметдинов тапшырылган эшне карусыз башкаралар, хуҗалык эшләреӊ җиренә җиткереп үтиләр. Аларны һәрчак руль артында күрәсең.

Тракторчы уңган егетләребездән Илгиз Хәлиуллин, Камил Хәрләмов, Рифкать Нуруллин һәм Нәкыйф Абдрахмановларның исеме мактауга лаек. Бүгенге көндә алар туңга сөрүдә эшлиләр. Кукуруз уруда эшләүче тынгысыз механизаторларыбыздан Рамил Сахипов, Нияз Зәйнуллин, фермага салам ташучы Илгизәр Гыйниятуллин, Ринат Мөхәрләмов, фураж чыгаручы уңган тракторчы Мидхәт Дәүләтшин, К - 700 тракторын идарә итүче Марат Шәһивәлиев һәм башкалар хуҗалыкның кайсы гына тармагында эшләсәләр дә үз эшләрен намус кушканча, тырышып, булсын дип башкаралар. Механизаторлар отряды яшьләрдән торса, бездә терлекчелектә дә бер дигән уңганнар эшли. Алар җәй буе малларны көтүче һәм бүген дә терлекләрне үз вакытында азык белән тәэмин итүчеләр Радик Нәбиуллин, Мансур Нәбиуллин, Әнвәр Шәйхиев, шулай ук Зәки Шәяхмәтов, Марат Ибраһимовлар. Алар кышлатуны уңышлы үткәрү өчен көчләрен кызганмыйлар. Ә инде терлекләрне фураж белән тәэмин итүче егетләребез Фәрит Галиуллин һәм Рамил Динмөхәммәтов турында да бары мактау сүзләре генә ишетәсең. Алар терлекчелеккә үзләреннән зур өлеш кертәләр.

Столярлык цехында ничә еллар инде үз эшләренең осталары Ринат Галиуллин, Исмәгыйль Яхинның хезмәтләре дә мактауга лаек. Әнә шулай һәр тармакта колхозыбыз уңганнары тырыш хезмәтләрен куеп, җиң сызганып эшлиләр.

**З.ИСМӘГЫЙЛОВА.**
**«Татарстан» КХАсы.**

# Угрылык кыйммәткә төшә

Район эчке эшләр бүлегенең ведомстводан тыш сак бүлеге башка хокук саклау органнары хезмәткәрләре кебек үк «Заслон», «Уңыш - 97» операцияләрендә катнашты. Аларның барышында сак бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан 150 вак урлаучы тотылды, алардан 1 млн. ярым сумлык байлык алынды һәм дәүләткә кире кайтартылды. Барлыгы 650000 сумлык җәмәгать милкен үзләштерүнең 20 очрагы кисәтелде.

Урлаучылык хокук бозучыларның иң киң таралганы булып тора һәм илнең икътисадына сизелерлек зыян китерә.

Әйтик, фермадагы сыер савучылар һәм азык ташучылар көн саен сыер алдына төшәргә тиешле күпмедер күләмдә фуражны, катнашазыкны, силосны һәм башкаларны янга калдыра барса... Мисал өчен, ведомстводан тыш сак бүлеге рейд үткәргәндә «Киекле» КХАдә 8 кешене тота һәм алардан 50 килограмм фуражны кире фермага кайтарта.

«Агрохимсервис» ярдәмче хуҗалыгында («Сөлчә») май аенда фермадан сөт урлаучы 7 кеше, август аенда яңа уңыш җыелгач 5 кеше - барысына 100 килограмм бодай белән тотыла. Әлбәттә, болар аерым мисаллар гына, ләкин тамчыдан күл җыела диләр бит. Һәм угрылыкны тамырдан кисәтү, юкка чыгару бары тик сак органнары көченнән генә килә торган эш түгел. Хуҗалык җитәкчеләре турыдан - туры үз вазифаларын үтәү йөзеннән хуҗалыкларында катгый исәп алып барырга һәм җәмәгать милкеннән явызларча файдаланучыларга карата кискен чаралар күрергә тиешләр.

**А.ЛОГИНОВ,**
**ведомстводан тыш сак бүлеге өлкән инспекторы.**

## *Мәктәп юбилеена рәхим итегез!*

***6 ноябрь көнне 10.00 сәг.тә Тимерлек урта мәктәбендә аның 20 еллыгына багышланган тантана була. Мәктәпне тәмамлаучыларны бәйрәмгә чакырабыз.***

Мәктәп администрациясе.



# КОТЛЫЙБЫЗ!

Ноябрь аенда гаиләбезнең кадерле кешеләре - Салдакай авылында яшәүче әтием, бабабыз **Минвәгыйзь Мортаза улы Мортазин**, Колбай Мораса авылында яшәүче кайнатам, дәү әтиебез **Нәсәт Хәммәдрәхим улы Рәхимов,** тормыш иптәшем, әтиебез **Азат Нәсәт улы Рәхимовның** туган көннәре.

Һәлакәтләр сезне читләп үтсен,
Күңелләргә кайгы тулмасын.
Ходай сезгә озын гомер бирсен,
Шатлыкларның чиге булмасын.

**Иң изге теләкләр белән Миңнур, Радик, Ришат.**

Ноябрь аенда тормыш иптәшем **Хәсәншин Әнәснең,** кызым **Зәлидәнең,** оныгым **Адельнең** туган көннәре.

Күңел күкләрегез һәрчак аяз булсын,
Читләп үтсен сагыш - борчулар.
Тигез гомер, сәламәтлек,
Зур бәхетләр юлдаш булсыннар.

**Изге теләкләр белән: әниегез, Лена.**

# *Хатын-кыз ир-аттан акыллыракмы?*

Бу сорауга Көнбатышта басылып чыккан «Җенес һәм ми» дигән китап җавап бирә. Аның авторлары - ирле - хатынлы психологлар Ио Дурден - Смит һәм Диана де Симоне. Бу гаилә Америка һәм Европа буйлап йөреп, кешенең баш миен һәм үз - үзен тотышын өйрәнүче күренекле галимнәр белән очрашып сөйләшүләргә өч ел гомерен сарыф итә. Бу интервьюларның иң мөһим нәтиҗәсе булып шундый йомгак ясала: ир - атның баш мие хатын - кызныкыннан туганда ук нык аерылып тора.

* Хәтта бертөрле киендереп, нәкъ бер үк төрле уенчыклар бирсәгез дә, малай - малай булып, кыз - кыз булып кала. Тикшеренүчеләрнең нәтиҗәсе шундый.

* Моның нигезе булып, минең гипоталамус дип аталучы нәни генә бер өлеше тора. Гипоталамус ир - атта һәм хатын - кызда төзелеше һәм функциясе ягыннан аерыла.

* Хатын - кыз мие ирләрнекенә караганда шактый ук кечкенә булса да, аның төзелеше яхшырак һәм ул ирләр миенә караганда тизрәк, әйбәтрәк эшли икән.

* Менә шундый «тигезсезлекнең» берничә мисалы:

алдан сиземләү хатын - кызга биологик мирас буларак күчә, ягъни туганда ук ми белән бергә бу сәләт тә була;

хатын - кыз күпкә хисчәнрәк, ул үз тирәсендәгеләрнең кәефе үзгәрүен шунда ук тоя, һәрбер ялган информацияне шунда ук тотып ала;

хатын - кызлар, кагыйдә буларак, тел өлкәсендә ирләргә караганда күпкә сәләтлерәк. Аларның сөйләме катлаулылыгы һәм бөтенлеге белән аерылып тора. Алар грамматикада һәм чит телләр өйрәнүдә ирләргә караганда шактый көчле.

* Хатын - кызның мондый искиткеч сыйфатлары, үзегез дә сизгәнсездер, буш урында гына барлыкка килмәгән. Боларның сәбәбе - баш миенең телләр белән, үзләштерү һәм күргән образларны анализлау белән «җитәкчелек итүче» нык үскән сул як ярымшары.

* Хатын - кызлар шулай ук искә, тавышка һәм кагылуларга да бик сизгер.

* Баш мие генә түгел, хатын - кызның башка әгъзалары да ирләрнекенә караганда күпкә чыдам. Хатын - кыз инфекциянең дә кайбер төрләренә бирешми.

* Барлык шушы өлкәләрдә хатын - кызның ирләргә караганда «башлырак» булуының сәбәбе нидә соң? Галимнәрнең фараз итүенә караганда, моның сәбәбе баш миенең кәүсәсендә. Ә ул хатын - кызларда ирләрнекенә караганда юанрак.

* Тикшеренүләр күрсәткәнчә, күпчелек йортларда бүгенгә кадәр гаилә башлыгы булып ирләр тора. Иң мөһим карарларны күпчелек очракта (80 процент!) ул кабул итә. Күз алдына китерә аласызмы, үзенең ярым - йорты сул ярымшары белән ул нинди генә карарлар кабул итмәскә мөмкин!

**(«Юлдаш» тан).**


## *Идел Буе региональ наркология үзәге*

*Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.* ***Табиб М.Б.Багрянцев.***

**Бездә генә!**

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, җомга көннәрендә, 7, 21ноябрьдә көндезге сәгать 2дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.

## ТАБЛЕТКАЛАРСЫЗ ДӘВАЛАУ

**«Магнит табибы» сезгә күп авырулардан арынырга, кәефегезне яхшыртырга булыша.**

**МАГНИТЛЫ АЛКАЛАР (КЛИПСЫЛАР) күпләрне баш авыртуыннан арындырыр, 20 минут эчендә кан басымын нормальләштерер, һава торышы кинәт үзгәргәндә булышыр. Клипсылар арыганлыкны бетерәләр, кәефне яхшырталар.**

**Әгәр сез ашказаны - эчәк авыруыннан, бөер ташларыннан, урологик һәм гинекологик чирләрдән интегәсез икән, сезгә һичшиксез МАГНИТОТРОННАР кирәк. Аш алдыннан магнитлы бүрәнкә аша үткәрелгән 100 гр. су гастрит, бөердә ташлар, урологик авырулар вакытында шифалы тәэсир ясый, организмның ныклыгын күтәрә, йокыны ныгыта. Магнит бүрәнкәсе аша уздырылган спиртлы эчемлекләр махмыр синдромы бирмиләр.**

**Яңалык! МАГНИТОПУНКТИР БРАСЛЕТЫ - арыганлыкны һәм стрессларны алу, йөрәк эшчәнлеген һәм артериаль кан басымын стабильләштерү, иммун системасын активлаштыру, йокыны һәм эчке органнар эшчәнлеген нормалаштыру өчен нәтиҗәле чара.**

**МАГНИТОТРОН - 1 (РЕКТАЛЬ) хроник простатит, ирләрнең кысырлыгы, эррекция бозылу, гемморойны дәвалаганда кулланыла.**

**МАГНИТОТРОН - 2 (ВАГИНАЛЬ) хатын - кызларга фригидлылык, эррозия, менструаль цикл бозылу, климактерик невроздан булыша.**

**«БИОМАГ» МАГНИТ ОЛТЫРАКЛАРЫ аякларның арыганлыгын һәм шешен алалар, иммун системаны активлаштыралар. Аяктагы төрле гөмбә авырулары, тромбофлебит, веналарның варикоз киңәюе вакытында булыша, кайчак ул иң өметсез хәлдә дә соңгы шанс була ала.**

**Хроник томау, өске тын юллары һәм гаймориттан КЛИПСЫ - ЛОР ярдәм итә.**

**МАГНИТ БИЛБАУ (АПЛИКАТОР) сезне радикулиттан, остеохондроздан коткарыр, ревматик авыртуларын бетерер, буыннарыгызның хәрәкәтен яхшыртыр һәм фармакологик препаратлардан баш тартырга булышыр.**

**Барлык магнитотроннар клиник сынау узганнар. РФ сәламәтлек саклау Министрлыгы аларны куллануларның киң мөмкинлеген раслады.**

**Серияле эшләп чыгару рөхсәт ителә. Дәвалау тәэсире 10 ел өзлексез куллануны гарантияли. «Градиен - магнитотрон» фәнни - тикшеренү институты тәкъдим итә:**

**Магнит билбавы - 30 мең сум.**
**Магнит бүрәнкәсе - 25 мең сум.**
**М - 1 (ректаль) - 15 мең.**
**М - 2 (вагиналь) - 20 мең.**
**Магнит клипсылар - 15 мең.**
**Клипсы - лор - 15 мең.**
**Браслет - 30 мең.**
**«Биомаг» олтырагы - 40 мең сум.**

Күргәзмә сату район үзәк шифаханәсе поликлиникасы холлында бары 3 нче ноябрь, дүшәмбе көнне бер генә сәгать (көндезге 11дән 12гә кадәр) була.

1996 елның 6 июлендә бирелгән № 30 - 03/ 404 лицензия.


## Белдерүләр

### САТАБЫЗ

**Шәһәр үзәгендә ике бүлмәле фатир.** Тел.: 2 - 11 - 49, 8дән 17 сәг.кә кадәр.

***

**Ленинградская урамында 30 нчы йорт.**

***

**1993 елгы ГАЗ - 31029, А - 76, 5 баскычлы тизлек күчерү тартмасы.** Тел.: 5 - 22 - 72.

***

**Әйбәт хәлдәге БМВ - 525, соры - зәңгәрсу төстә, металлик.** Тел.: 5 - 27 - 89.

***

**1995 елның сентябрендә чыккан «Нива - 21213».** Тел.: 5 - 22 - 87.

***

**1997 елгы ВАЗ - 21099, сапфир төсендә, металлик.** Адрес: Кошки авылы, Вокзальная ур., 12. Тел.: 2 - 15 - 21, 2 - 24 - 98.

***

**1995 елгы тентланган УАЗ - 3303.** Адрес: Аксубай эшчеләр поселогы, Профсоюзлар ур., 11 йорт.

***

**1991 елгы ГАЗ - 66, 18 мең км. юл үткән.**
«Иверия» кибетенә мөрәҗәгать итәргә.

### ТӨРЛЕСЕННӘН

**«Татнефть»нең «Б» категорияле, «Газпром», саклык банкы, «Лукойл», «ПУР», «Сургут», «Когалым», «Юганскнефтегаз» акцияләрен сатып алабыз.** Тел.: 5 - 37 - 69, лицензия номеры 747.

***

**1 нче мәктәп тарафыннан 1995 елда Абрамова Марина Александровна исеменә бирелгән А 0027060 номерлы аттестатны, югалу сәбәпле, гамәлдән чыккан дип санарга.**

***

**Парфенов Владимир исеменә бирелгән һәм29 октябрьдә базар мәйданында югалган ВАЗ һәм ГАЗ машиналарын теркәү турындагы һәм машина йөртү таныклыкларын бүләк бәрабәренә редакциягә (К.Маркс ур., 19) китереп бирүләрен сорыйбыз.**

***

**Иванов Алексей Александрович исеменә документлар белән сумка табучының бүләк бәрабәренә Московская ур., 48 - 2 адресы буенча кайтарып бирүләрен сорыйбыз.**

***

**Арзан һәм сыйфатлы итеп йорт, гаражлар төзибез.** Тел.: 5 - 16 - 25, Нәҗип.

***

**Линейная урамы буенча гараж, вагончык сатып алам.** Тел.: 5 - 24 - 97.


## «Наркодел»

**Алкогольгә бәйлелектән коткару өчен зыянсыз һәм эффектлы чәй. Анонимлык мөмкин. Район мәдәният йортына 3 ноябрьдә 11 сәгатьтән 13 сәг.кә кадәр мөрәҗәгать итәргә. Керү - бушлай.**

Лицензия № 000102, 28.09.95 елда Мәскәү ФД тарафыннан бирелгән.



БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА.**

Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.

Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2338 данә. 9420